ГЛАВА НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

“23 ” октябрь 2020 ел. — № 7

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Түбән Оча авылы, Мәктәп урамы, 9 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Оча торак пунктында авыл клубы бинасында 2020 елның 18 нче ноябрендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнар кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Оча торак пункты җирле әһәмияттәге юлларны чокырлар ремонтлау һәм грейдлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Түбән Оча торак пунктындагы җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;

- Түбән Оча торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башкарма комитетына Түбән Оча торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы: Р.Ж.Һәмизүллин